**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**СТАРОКУТУШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Свежухина, дом33, с.Старые Кутуши, 423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ИСКЕ КӨТЫШ
**ИСКЕ КӨТЫШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ** МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**СОВЕТЫ**
урамы,33 йорт, иске котыш авыл, 423116

Тел(84396)2-72-47 Skut.Cmn@tatar.ru

29.05.2024 ел № 100

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 30 июнендәге 79 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 30 июнендәге 79 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «2.6. Әлеге нигезләмәнең 2.5 өлешендә күрсәтелгән анкетадагы белешмәләрдән тыш, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырылган белешмәләр федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин.

1.2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.К.Митякин